# Гаяз Исхакый


Выполнила работу

Павлова Валерия


Гаяз Исхакый 1878 елның 22февралендә Казан губернасының Чистай өязе Яуширмә авылында Гыйлаҗетдин мулла гаиләсендә туа.




Әдәбиятка Гаяз шактый иртә килә. «Тәгаллемдә сәгадәт» [1] исемле беренче әсәрен 17 яшендә яза. 1902 елда «Ике йөз елдан соң инкыйраз [2]» исемле хыялый-публицистик повестен тәгәлли. 1905 елгы революциягә кадәр үк инде ул дистәгә якын хикәя һәм повесть, ике пьеса һәм «Теләнче кызы» исемле романының беренче кисәген тәмамлый һәм күбесен дөньяга чыгара.




1904 елны Казанга килеп, революцион хәрәкәткә кушылып китә. «Таң йолдызы» исемле газета чыгара башлый.




Г. Исхакый, хөкүмәткә каршы җинаятьтә гаепләнеп, 1906 елда кулга алына һәм Чистай төрмәсенә ябыла. Шунда «Зиндан» исемле автобиографик повестен яза. Аннары Архангель губернасына сөргенгә җибәрелә. Шушы авыр шартларда ул «Солдат» повестен, «Теләнче кызы» романының икенче кисәген, берничә пьеса яза. Романовлар династиясенең 300 еллыгы уңае белән игълан ителгән амнистия нигезендә 1913 елда азат ителә.



Г. Исхакый 1917 елның 22 ноябрендә Уфада Милли мәҗлестә катнаша. Ләкин ул милли мәсьәләнең хәл ителү рәвешен, гомумән, Совет властен кабул итә алмый һәм Ватаныннан китәргә мәҗбүр була.



1928—1939 елларда Берлинда яшәп, «Яңа милли юл» исемле журнал чыгара. 1935 елда Кытайда чыга башлаган «Милли байрак» газетасы шулай ук Г. Исхакый тырышлыгы белән дөньяга килә.



Сталинизм чоры башлану белән Исхакый шәхес культын, аның өере урнаштырган режимны матбугат аша рәхимсез утка тота.

Исхакый — татар театрының тууында, үсешендә зур урын тоткан шәхес. 1906 елның апрелендә аның «Өч хатын белән тормыш» , 1907 елда «Ике гыйшык» пьесасы сәхнәдә уйнала. «Алдым-бирдем» драмасы, татар сәхнә әсәрләреннән беренче буларак, 1914 елда Петербургта рус телендә бастырып чыгарыла. 1908—1912 елларда «Тартышу» , «Мөгаллим» , «Кыямәт» , «Җәмгыять» , «Зөләйха» кебек пьесалары дөнья күрә. Аның әсәрләрендә һәр милләт, үз телен, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен саклап, үзенә үзе хуҗа булып, мөстәкыйль яшәргә тиеш дигән фикер ята.

Талантлы прозаик, драматург, публицист, җәмәгать эшлеклесе Г. Исхакыйның әсәрләре озак еллар буе бикләп тотылса һәм эшчәнлеге бозып аңлатылса да, дөреслек җиңде, Г. Исхакый акланды. Аның бай тарихлы иҗаты укучыларга кире кайтты.

1991 елда Татарстан Язучылар берлеге Г. Исхакый исемендәге премия булдырды.
Әдип 1954 елда 76 яшендә вафат була һәм Төркиянең Истанбул шәһәрендә күмелә.


Рәхмәт карау
Минем презентация